**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 16 апрель № 235

г. Казань

«Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү буенча комиссия төзү хакында

«Россия Федерациясендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 ел, 29 декабрь, ФЗ-473 нче Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» 2015 ел, 22 июнь, 614 нче карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясен төзү турында» 2016 ел, 28 гыйнвар, 44 нче карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү буенча комиссия төзергә.

2. Бу карарга теркәлгән «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү буенча комиссия хакындагы нигезләмәне һәм аның составын расларга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 16 апрель, 235 нче карары белән расланды

**«Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү буенча комиссия хакында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү буенча комиссиянең (алга таба – Комиссия) төп бурычларын һәм эшен оештыру тәртибен билгели.

2. Комиссия үзенең эшчәнлеген «Россия Федерациясендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 ел, 29 декабрь, ФЗ-473 нче Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» 2015 ел, 22 июнь, 614 нче карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясен төзү турында» 2016 ел, 28 гыйнвар, 44 нче карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карары нигезендә гамәлгә ашыра.

3. Комиссия үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының закон һәм башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

4. «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү (алга таба – Килешү) төзүгә гаризаларны карап тикшерү һәм Килешү төзү мөмкинлеге яки төзүдән баш тарту хакында карарлар кабул итү Комиссиянең төп бурычлары булып тора.

5. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль структураларыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук башка оешмалардан кирәкле документлар һәм мәгълүмат соратып алырга;

Комиссия эшенә мәнфәгатьле федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль структуралары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары белгечләрен, фәнни-тикшеренү һәм белем бирү оешмалары, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка

оешмалар экспертларын һәм консультантларын, шулай ук составы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыгы белән раслана торган бәйсез экспертлардан торган Комиссиянең эксперт төркемен җәлеп итәргә.

6. Комиссия эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итүне Комиссия рәисе гамәлгә ашыра.

7. Комиссия рәисе:

Комиссия утырышының датасын, вакытын һәм урынын билгели;

Комиссия утырышының көн тәртибен раслый;

Комиссия утырышларын үткәрә;

Комиссия утырышы беркетмәсен раслый;

Комиссия составын үзгәртү турында тәкъдимнәр кертә.

8. Комиссия рәисе булмаган очракта аның вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен Комиссия рәисе урынбасары башкара.

9. Комиссиянең җаваплы секретаре:

Комиссия утырышының көн тәртибен, документлар һәм карарлар проектларын әзерли, Комиссия утырышының беркетмәсен алып баруны һәм рәсмиләштерүне тәэмин итә;

Комиссия рәисе йөкләмәсе буенча дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм башка оешмаларга Комиссия утырышында карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча мәгълүмат һәм материаллар кертү турында сорату кәгазе җибәрә;

Комиссия әгъзаларына, мәнфәгатьле органнарга һәм оешмаларга, чакырылган затларга булачак Комиссия утырышы турында хәбәр итә;

Комиссия утырышында карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча мәгълүмат һәм материалларны Комиссиянең эксперт төркеменә җибәрүне тәэмин итә;

Комиссия утырышы беркетмәләрен, аның эшчәнлегенә бәйле башка материалларны саклауны һәм Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итә;

Комиссия кабул иткән карарлар турында мәнфәгатьле затларга хәбәр итә;

Комиссия утырышында кабул ителгән карарларның үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра;

Комиссия эшчәнлегенең оештыру-техник тәэмин ителүен тормышка ашыра.

## II. Комиссия утырышларын үткәрү тәртибе

10. Комиссия утырышлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибенең 16 – 25 нче пунктларында күздә тотылган тәртип һәм шартлар нигезендә үткәрелә.

11. Комиссия утырышының көн тәртибендәге мәсьәләләрне карап тикшерү түбәндәге эзлеклелектә гамәлгә ашырыла:

Килешү төзергә планлаштыра торган юридик зат (алга таба – Гариза бирүче) вәкиленең Комиссиянең көн тәртибе мәсьәләсе буенча чыгышы;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының, тармак министрлыкларның һәм Комиссиянең эксперт төркеменең бәяләмәләрен тыңлау;

Гариза бирүченең чыгышы буенча фикер алышу һәм Гариза бирүченең Комиссия әгъзалары сорауларына җавап бирүе;

Гариза бирүченең чыгышы йомгаклары буенча Комиссия әгъзаларының фикерләрен тыңлау;

Комиссия утырышының көн тәртибе мәсьәләсе буенча тавыш бирү;

Комиссия утырышының көн тәртибе мәсьәләсе буенча тавышларны санау һәм йомгак ясау;

Комиссия утырышының көн тәртибе мәсьәләсе буенча тавыш бирү йомгаклары буенча нәтиҗәләрне игълан итү.

---

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 16 апрель, 235 нче карары белән расланды

**«Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Халиков Илдар Шәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Комиссия рәисе |
| Здунов Артём Алексеевич | Татарстан Республикасы икътисад министры, Комиссия рәисе урынбасары |
| Кропотова Наталия Анатольевна | Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, Комиссия секретаре (килешү буенча) |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Әхмәтов Марат Готыф улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| Әбҗәлилова Ләйсән Рәхим кызы | «Кама инновацион территориаль-җитештерү кластеры» коммерциячел булмаган партнерлыгы» ассоциациясе вице-президенты (килешү буенча) |
| Агеев Шамил Рәхим улы | Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Беляев Радмир Илдар улы | Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Болотаев Сергей Георгиевич | «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциячел булмаган оешмасы директоры (килешү буенча) |
| Вафин Эдуард Яфас улы | Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге – дәүләт учреждениесе идарәчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Гайзатуллин Радик Рәүф улы | Татарстан Республикасы финанс министры |
| Гайнетдинов Ренат Вагыйз улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы |
| Галиәкбәрова Әлфинур Азат кызы | Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Финанс идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Гатина Лилия Назыйм кызы | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре буенча инспекция башлыгы (килешү буенча) |
| Исхаков Илмир Зөфәр улы | Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Архитектура, шәһәр төзелеше һәм торак үсеше идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| Мәһдиев Наил Гамбәр улы | Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Миңнуллин Юлай Рим улы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының икътисадый анализ һәм проектлар белән идарә итү бүлеге мөдире |
| Миңнуллина Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе |
| Сафиуллин Марат Әдип улы | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Стеблов Максим Георгиевич | «Мастер» Кама индустриаль паркы» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Таркаева Наталья Александровна | Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Фәйзуллин Ирек Әнвәр улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Фәттахов Эдуард Рафаил улы | Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы Чаллы шәһәрендәге идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Фатыйхова Эльвира Назыйф кызы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының муниципаль берәмлекләрнеүстерү бүлеге мөдире |
| Хәлиуллина Жанна Евгеньевна | «КАМАЗ» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары – корпоратив директор (килешү буенча) |
| Шәвәлиев Дилүс Рәсим улы | «Татарстан Республикасының Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе |
| Шакиров Ленар Мөзәят улы | «Россия Социаль иминиятләштерү фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге» дәүләт учреждениесенең 9 нчы филиалы директоры (килешү буенча) |
| Шигин Иван Александрович | Чаллы шәһәре һәм «Закамье» төбәге Сәүдә-сәнәгать палатасы генераль директоры (килешү буенча). |

F:\KARAR\2016\235_2.doc